**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5766**
**01.09.2021**

Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 9 декабрендәге 6589 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 3530 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 5760 номерлы, 2020 елның 17 августындагы 3995 номерлы, 2021 елның 15 июнендәге 4013 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Объект хуҗасы ачыкланмаган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары демонтажлау турында күрсәтмәнең күчермәсен объектка урнаштыралар, бу хакта күрсәтмә бланкында билгеләп куела һәм бер эш көне эчендә күрсәтмәнең күчермәсен «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыралар.»;

2) 10.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру датасы;»;

3) 11 пунктта «, «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарылган» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Объект демонтажланган көннән башлап өч эш көне эчендә, объектны демонтажлау датасын һәм вакытын, объектны һәм андагы мөлкәтне объект хуҗасына бирү тәртибен күрсәтеп, демонтажлау турындагы мәгълүматны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны район хакимиятенең вазыйфаи затлары тәэмин итә.»;

5) 35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. Объект хуҗасы ачыкланмаган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары күрсәтмәнең күчермәсен турыдан-туры объектка урнаштыралар, бу хакта күрсәтмә бланкында

билгеләп куела һәм бер эш көне эчендә күрсәтмәнең күчермәсен «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыралар.»;

6) 36 пунктта «, «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарылган» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 42 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42. Мондый объектлар махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына күчерелгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә, Башкарма комитетының тиешле район хакимиятенең вазыйфаи затлары объект хуҗасына 8 нче кушымтада каралган форма буенча белдерү кәгазе җибәрәләр һәм мондый белдерүне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыралар.»;

8) Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнләмәгә 2 нче кушымтада «күрсәтмәне «Челнинские известия» газетасында бастыру һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә 7 нче кушымтада «күрсәтмәне «Челнинские известия» газетасында бастыру һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыклары И.Н. Галимовка, В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов